**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 23 июнь № 417

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлеге турында» 2012 ел, 21 июнь, 539 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 2 октябрь, 713 нче; 2014 ел, 26 март, 187 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 18 июнь, 412 нче; 2016 ел, 18 ноябрь, 851 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункциональ үзәкләре базасында күрсәтелә торган дәүләт, муниципаль һәм башка хезмәтләрнең якынча исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
| 1. | Күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастр исәбенә алу һәм (яки) күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирү»; |

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы» бүлекчәсе үз көчен югалткан дип санарга;

«Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсенең 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә, иминият кертемнәре түләүчеләргә һәм салым агентларына гамәлдәге салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар, салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләр, җыемнар түләүчеләр, иминият кертемнәре түләүчеләр һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары турында, салым органнары һәм аларның вазыйфаи затлары вәкаләтләре турында (салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәү турында белешмә соратып алу һәм бирү өлешендә) түләүсез мәгълүмат бирү (шул исәптән язма рәвештә)»; |

«Россия Федерациясе Социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлеге – дәүләт учреждениесе» бүлегенең 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5. | Инвалидларны техник тернәкләндерү чаралары һәм (яки) хезмәт күрсәтүләр һәм ветераннар арасыннан булган гражданнарның аерым категорияләрен протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре белән тәэмин итү, шулай ук инвалидлар үзләре сатып алган техник тернәкләндерү чаралары (ветераннар тарафыннан протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре) һәм (яки) түләнгән хезмәт күрсәтүләр өчен компенсация һәм инвалидларның озатып йөрүче этләрне карап тоту һәм ветеринария хезмәте күрсәткән өчен чыгымнарына еллык акчалата компенсация түләү (инвалидларга техник тернәкләндерү чаралары һәм (яки) хезмәт күрсәтүләр һәм ветераннар арасыннан булган гражданнарның аерым категорияләренә протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре бирү, шулай ук инвалидлар үзләре сатып алган техник тернәкләндерү чаралары (ветераннар тарафыннан |

| | |
|---|---|
| | протезлар (теш протезларыннан тыш), протез-ортопедия эшләнмәләре) һәм (яки) түләнгән хезмәт күрсәтүләр өчен компенсация һәм инвалидларның озатып йөрүче этләрне карап тоту һәм ветеринария хезмәте күрсәткән өчен чыгымнарына еллык акчалата компенсация түләү турында гариза бирү өлешендә)»; |

«Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында территориаль идарәсе» бүлекчәсендә:

2 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

«Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары хезмәтләре» дигән III бүлек үз көчен югалткан дип санарга;

«Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» дигән IV бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 16 – 17 пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «16. | Криптографик мәгълүмат саклау чарасы белән җиһазландырылган цифрлы тахограф өчен йөртүче картасын әзерләүгә гаризалар кабул итү |
| 17. | Гражданнарга дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына кергән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре бирүгә гаризалар кабул итү»; |

«Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте хезмәтләре» дигән IV.1 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «IV.1. «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте хезмәтләре | |
|---|---|
| 1. | Билгеләнгән параметрлар буенча «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлештә каралган дәүләт һәм муниципаль мөлкәт исемлекләренә кертелгән һәм өченче затлар хокукларыннан ирекле күчемсез мөлкәт турында мәгълүмат сайлап алу хезмәте |
| 2. | Билгеләнгән параметрлар буенча «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән конкрет заказчыларның товарларын, эшләрен, хезмәтләрен, шул исәптән инновация продукциясен, югары технологияле продукциясен сатып алуда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру турында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 3. | Билгеләнгән параметрлар буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү формалары һәм шартлары турында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 4. | «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыятенең укыту программалары буенча тренинглар турында һәм |

| | |
|---|---|
| | әлеге тренингларда катнашуга электрон язылу хакында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 5. | Билгеләнгән параметрлар буенча агымдагы елда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларыннан «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон нигезендә билгеләнгән конкрет һәм аерым заказчыларның сатып алулары күләмнәре һәм номенклатурасы турында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 6. | Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмалар турында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә күрсәтелә торган ярдәм чаралары һәм шартлары хакында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 7. | «КУЭ бизнес-навигаторы» мәгълүмат-аналитика порталында теркәү хезмәте; |

V бүлектә:

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе | |
|---|---|
| 1. | Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастр исәбе һәм (яки) күчемсез мөлкәткә хокукларны дәүләт теркәвенә алу |
| 2. | Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында булган мәгълүматларны бирү»; |

«Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы» «бүлекчәсе үз көчен югалткан дип санарга;

«Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы» бүлекчәсенә түбәндәге эчтәлекле 2 – 3 нче пунктлар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «2. | Хөкемгә тартылган һәм (яки) җинаять эзәрлекләвенә дучар булу (булмау) турында яисә җинаять эзәрлекләве туктатылу хакында белешмәләр бирү |
| 3. | Затның табиб билгеләмәгән наркотик яки психотроп матдәләр яисә яңа потенциаль куркыныч матдәләр кулланганга административ җәзага тартылган булуы яки булмавы турында белешмәләр бирү»; |

«Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе» бүлекчәсенең 5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «5. | Салым түләүчеләргә, җыемнар түләүчеләргә, иминият кертемнәре түләүчеләргә һәм салым агентларына гамәлдәге салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәре, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актлар, салымнар һәм җыемнар, иминият кертемнәрен исәпләү һәм түләү тәртибе, салым түләүчеләр, җыемнар түләүчеләр, иминият кертемнәре түләүчеләр һәм салым агентларының хокуклары һәм бурычлары турында, салым органнары һәм аларның вазыйфаи затлары вәкаләтләре турында (салым түләүченең (җыемнар түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычларын үтәү турында белешмә соратып алу һәм бирү өлешендә) түләүсез мәгълүмат бирү (шул исәптән язма рәвештә)»; |

«Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасындагы территориаль идарәсе» бүлекчәсендә:

бүлекчә исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт мөлкәте белән идарә итү федераль агентлыгының Татарстан Республикасында һәм Ульяновск өлкәсендәге төбәкара территориаль идарәсе»;

2 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

«Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте хезмәтләре» бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыяте» | |
|---|---|
| 1. | Билгеләнгән параметрлар буенча «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 ел, 24 июль, ФЗ-209 нчы Федераль законның 18 статьясындагы 4 өлештә каралган дәүләт һәм муниципаль мөлкәт исемлекләренә кертелгән һәм өченче затлар хокукларыннан ирекле күчемсез мөлкәт турында мәгълүмат сайлап алу хезмәте |
| 2. | Билгеләнгән параметрлар буенча «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән конкрет заказчыларның товарларын, эшләрен, хезмәтләрен, шул исәптән инновация продукциясен, югары технологияле продукциясен сатып алуда кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының катнашуын оештыру турында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 3. | Билгеләнгән параметрлар буенча кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү формалары һәм шартлары турында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 4. | «Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү федераль корпорациясе» акционерлык җәмгыятенең укыту программалары буенча тренинглар турында һәм әлеге тренингларда катнашуга электрон язылу хакында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 5. | Билгеләнгән параметрлар буенча агымдагы елда кече һәм урта эшмәкәрлек |

| | |
|---|---|
| | субъектларыннан «Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товар-лар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында» 2011 ел, 18 июль, ФЗ-223 нче Федераль закон нигезендә билгеләнгән конкрет һәм аерым заказчыларның сатып алулары күләмнәре һәм номенклатурасы хакында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 6. | Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмалар турында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына федераль, региональ һәм муниципаль дәрәҗәләрдә күрсәтелә торган ярдәм чаралары һәм шартлары хакында мәгълүмат бирү хезмәте |
| 7. | «КУЭ бизнес-навигаторы» мәгълүмат-аналитика порталында теркәү хезмәте; |

түбәндәге эчтәлекле «Татарстан Республикасы ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе», «Иминият оешмалары хезмәтләре», «Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы», «Газпром межрегионгаз Казан» акционерлык җәмгыяте», «Водоканал» Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиесе», «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте», «Генерирующая компания» ачык акционерлык җәмгыяте», «Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр» дигән бүлекчәләрне өстәргә:

| «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе | |
|---|---|
| 1. | Кредит һәм башка финанс ресурслары алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирү |
| 2. | Финансларны планлаштыру мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 3. | Эшчәнлекне маркетинг ягыннан тәэмин итү һәм бизнес-планлаштыру мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 4. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген патент-лицензия белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 5. | «Җиһазлар сатып алу белән бәйле чыгымнарны субсидияләү (50/50 программасы)» программасы кысаларында дәүләт финанс ярдәме алуга документларны кабул итү, дәүләт ярдәме алганда булышлык күрсәтү, нәтиҗәләр турында мәгълүмат бирү, дәүләт ярдәме күрсәтү турында шартнамә төзегәндә булышлык күрсәтү |
| 6. | «Россия кредит оешмаларыннан алган кредитлар буенча процентларны түләүгә бәйле чыгымнарны субсидияләү» программасы кысаларында дәүләт финанс ярдәме алуга документларны кабул итү, дәүләт ярдәме алганда булышлык күрсәтү, нәтиҗәләр турында мәгълүмат бирү, дәүләт ярдәме күрсәтү турында шартнамә төзегәндә булышлык күрсәтү |
| 7. | «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының җиһазлар лизингы шартнамәсе (лизинг-грант) буенча беренче кертемне (аванс) түләүгә чыгымнарын |

| | |
|---|---|
| | субсидияләү» программасы кысаларында дәүләт финанс ярдәме алуга документларны кабул итү, дәүләт ярдәме алганда булышлык күрсәтү, нәтиҗәләр турында мәгълүмат бирү, дәүләт ярдәме күрсәтү хакында шартнамә төзегәндә булышлык күрсәтү |
| 8. | Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган программалар һәм ярдәмче программалар буенча дәүләт финанс ярдәме чараларын сайлап алу |
| 9. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген хокукый тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 10. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының производство компетенцияләрен эре корпорация заказчылары таләпләренә кадәр үстерү буенча дәүләт ярдәме чараларын сайлап алу һәм консультация бирү |
| 11. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Татарстан Республикасының эре эшмәкәрлек предприятиеләре сатып алулары турында мәгълүмат бирү |
| 12. | Компетенцияләрне киңәйтү, җитештерүне камилләштерү яки диверсификацияләү, сертификатлар, лицензияләр һәм башка документлар (рөхсәт кәгазьләре, керүгә рөхсәт) алу юлы белән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары һәм эре эшмәкәрлек предприятиеләре арасында производство кооперациясен үстерү мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 13. | Инновацияләр һәм сәнәгать җитештерүе өлкәсендә ярдәм күрсәтү (производство мәйданнарын сайлап алу, җиһазлар сайлап алу) |
| 14. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары эшчәнлеген үстерүгә булышлык күрсәтү максатларында башка консультация хезмәтләре |
| 15. | Эшмәкәрлекне һәм үз эшеңне башлап җибәрүне популярлаштыруга юнәлдерелгән укыту чараларын гамәлгә ашыру |
| 16. | Товарлар, эшләр һәм хезмәтләрне сертификатлаштыруны оештыру хезмәтләре |
| 17. | Мөлкәт ярдәм чаралары турында консультация бирү |
| 18. | Ташламалы шартларда бизнес-инкубацияләү үзәге биналарында, агросәнәгать паркларында, сәнәгать паркларында (мәйданчыкларында), махсус икътисадый зоналарда урнашу мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 19. | Тышкы икътисадый эшчәнлек мәсьәләләре буенча консультация ярдәме |
| 20. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен бизнесны чит илдә оештыру буенча белем бирү семинарлары һәм тренинглар оештыру һәм үткәрү |
| 21. | Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының чит илдәге потенциаль партнерларына эшлекле миссияләрен оештыру, шулай ук Татарстан эшмәкәрләренең чит ил конференцияләрендә һәм башка чит ил чараларында катнашуын оештыруда булышлык күрсәтү |
| 22. | Продукцияне чит ил базарларына чыгаруда булышлык күрсәтү |

| | |
|---|---|
| 23. | Экспортчы эшмәкәрләргә тышкы икътисадый эшчәнлек мәсьәләләре, тышкы икътисадый эшчәнлеккә бәйле халыкара чаралар буенча мәгълүмати-аналитик ярдәм күрсәтү, экспортчы предприятиеләр ихтыяҗларын өйрәнү, шулай ук Татарстан җитештерүчеләренең продукциясе экспорты өчен өстенлекле илләрне өйрәнү эше |
| 24. | Россия Федерациясеннән читтә гамәлгә ашыру максатларында продукцияне (эшләрне, хезмәтләрне) сертификатлаштыру (лицензияләү, патентлау) |
| 25. | Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештерә торган товарларны эчке базарларга чыгару |
| 26. | Экспортка юнәлдерелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары җитештерә торган товарларны тышкы базарларга чыгару |
| 27. | Экспортка юнәлдерелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының күргәзмәләрдә, чараларда, акцияләрдә (шул исәптән халыкара) катнашуын оештыру мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 28. | Экспортка юнәлдерелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына маркетинг тикшеренүләре буенча хезмәтләр күрсәтү |
| 29. | «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясендә заемга алганда поручительлек бирү шартлары һәм рәсмиләштерү тәртибе турында мәгълүмат |
| 30. | «Кредит тарихлары илкүләм бюросы» акционерлык җәмгыятенең бердәм базасыннан мәгълүмат бирү |
| 31. | Кредит тарихларының мәгълүмат базасыннан кредит хисаплары бирү |
| 32. | Тиешле залог шартнамәләре буенча автомобильләр залогы турында мәгълүматлар базасына мәгълүмат кертү буенча хезмәтләр күрсәтү |
| 33. | Интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләреннән файдалану коммерцияләштерү турында мәгълүмат бирү |
| 34. | Биотехнологияләр инжинирингы, производстволарны проектлаштыру, продукцияләрне тәкъдим итү, партнерлар эзләү, модернизация программаларын әзерләү һәм тормышка ашыру, яңадан техник җиһазландыру өлкәсендә хезмәтләр күрсәтүче оешмалар турында мәгълүмат бирү |
| 35. | Продукцияне тәкъдим итү, маркетинг тикшеренүләре буенча хезмәтләр күрсәтүче оешмалар турында мәгълүмат бирү |
| 36. | Инновацион эшмәкәрлек проектларын тәкъдим итү буенча мәгълүмати ярдәм күрсәтү |
| 37. | Аккредитацияләнгән сәнәгать мәйданчыкларында производстволар урнаштыру мөмкинлеге турында мәгълүмати хезмәтләр |
| 38. | Инновация проектларын гамәлгә ашыруда, производствога яңа технологияләр кертүдә булышлык күрсәтүче оешмалар белән хезмәттәшлек итү мәсьәләләре буенча консультация бирү |
| 39. | «Илебездә җитештерелгән робот техникасын прототиплаштыру һәм файдалануга кертү үзәге» акционерлык җәмгыяте белән производстволарны проектлаштыру һәм робот техникасы продукциясен җәелдерү өлешендә эшчәнлек һәм хезмәттәшлек итү тәртибе турында мәгълүмат бирү |

| | |
|---|---|
| 40. | Франчайзингтан файдалану тәртибе һәм мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирү |
| 41. | Эшмәкәрләр өчен «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү фонды» коммерциячел булмаган микрокредит компаниясе катнашында оештырылган квалификацияне күтәрү программалары турында мәгълүмат бирү |
| 42. | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен кредит оешмаларында хисап счеты ачу мәсьәләләре буенча консультация хезмәтләре |
| 43. | Гариза бирүчеләргә эквайринг (сәүдә эквайрингы, интернет-эквайринг) хезмәтләре буенча консультация бирү |
| 44. | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә шикаятьләр җибәрүдә ярдәм күрсәтү |
| 45. | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чаралары үткәрелгәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә белдерелә торган мәҗбүри таләпләр исемлеге турында мәгълүмат бирү |
| 46. | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чаралары үткәрелгәндә юридик затлардан һәм шәхси эшмәкәрләрдән сорала торган документлар исемлеге турында мәгълүмат бирү |
| 47. | Төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан контроль-күзәтчелек чаралары үткәрелгәндә юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә белдерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозган өчен санкцияләр турында мәгълүмат бирү |
| 48. | Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының рәсми сайтында урнаштырылган эшмәкәрлек субъектларына мөнәсәбәтле тикшерүләр үткәрүнең еллык җыелма планы нигезендә юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләрнең планлаштырылган тикшерүләре турында мәгълүмат бирү |
| Иминият оешмалары хезмәтләре | |
| 1. | Физик зат мөлкәтен иминиятләштерү |
| 2. | Юридик зат мөлкәтен иминиятләштерү |
| 3. | Автотранспорт чараларын ирекле иминиятләштерү (КАСКО) |
| 4. | Бәхетсезлек очракларыннан иминиятләштерү |
| 5. | Ирекле медицина иминияте |
| 6. | Чит илгә чыгучы гражданнарның көтелмәгән чыгымнарына бәйле финанс куркынычларны иминиятләштерү |
| 7. | Йөкләр ташуны иминиятләштерү |
| 8. | Пассажирлар йөртүченең граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү (ОСГОП) |
| 9. | Юридик затларның өченче затларга зыян китергән өчен граждан җаваплылыгын иминиятләштерү |

| | |
|---|---|
| 10. | Физик затларның өченче затларга зыян китергән өчен граждан җаваплылыгын иминиятләштерү |
| 11. | Куркыныч объектта һәлакәт нәтиҗәсендә зыян китергән өчен куркыныч объект хуҗасының граждан җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү |
| 12. | Хайваннарны иминиятләштерү |
| 13. | Ипотека иминияте |
| 14. | Төзелеш-монтаж куркынычларын иминиятләштерү |
| 15. | Үзләре көйли торган оешмалар әгъзаларының граждан җаваплылыгын иминиятләштерү |
| 16. | Су транспортын иминиятләштерү |
| 17. | Суднолар хуҗасының граждан җаваплылыгын иминиятләштерү |
| Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү өлешендә) | |
| 1. | Бухгалтерлык консультацияләре, бухгалтерлык исәбенә кую һәм алып бару, керемнәр турында декларацияләр һәм бухгалтерлык исәп-хисабы төзү |
| 2. | Логотибын һәм фирма стилен эшләү |
| 3. | Сайтны эшләү һәм җәелдерү |
| 4. | Патентны һәм товар билгесен теркәү |
| 5. | Россиядә һәм чит илдә партнерлар һәм клиентлар эзләүдә булышлык күрсәтү |
| 6. | Халыкара стандартларга һәм банк таләпләренә туры килгән инвестиция проектларын әзерләүдә булышлык күрсәтү |
| 7. | Хуҗалык-финанс эшчәнлеген анализлау, эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектларының активларын һәм пассивларын бәяләү |
| 8. | Бәйсез аудит, бухгалтерлык консультацияләре; салым органнарында предприятиеләр мәнфәгатьләрен белдерү һәм яклау, салым тикшерүләре актларын анализлау |
| 9. | Күчемсез мөлкәтне, җиһазларны бәяләү |
| 10. | Эшмәкәрләр мәнфәгатьләрен хокукый яклау |
| 11. | Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы каршындагы Килештерү процедураларын үткәрү буенча арадашчылар коллегиясе хезмәтләре (медиация) |
| 12. | Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән бәхәсле мәсьәләләрне һәм эшмәкәрлек проблемаларын хәл итү буенча хезмәттәшлек итү |
| 13. | «Татарстан Республикасы Инвестиция-венчур фонды» коммерциячел булмаган оешмасы, җаваплылыгы чикләнгән «Татарстан Республикасы кече бизнесының лизинг компаниясе» җәмгыяте, Татарстан Республикасы Банклар ассоциациясе, «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциячел булмаган оешмасы белән эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтүнең финанс инструментлары мәсьәләләре буенча хезмәттәшлек итү |
| 14. | Партнерлар эзләү мәсьәләләре буенча төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек |

| | |
|---|---|
| 15. | Инвесторлар эзләүдә булышлык күрсәтү |
| 16. | Сәүдә-икътисадый миссияләр үткәрү, эшлекле визитларны тәэмин итү; махсус вакыйгаларны оештыру: тематик һәм матбугат конференцияләре, эшлекле очрашулар, «түгәрәк өстәлләр» утырышлары |
| 17. | Чит телләрдән/чит телләргә тәрҗемәләрне гамәлгә ашыру |
| 18. | Күргәзмәләрдә һәм конгресс чараларында катнашуда булышлык күрсәтү |
| 19. | Стажировкалар, квалификацияне күтәрү курслары, белем бирү семинарлары һәм вебинарлар оештыру һәм үткәрү |
| «Газпром межрегионгаз Казан» акционерлык җәмгыяте»» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү өлешендә) | |
| 1. | Газны исәпләү узеллары проектларын килештерү |
| 2. | Газны исәпләү узелларын коммерция эксплуатациясенә кертү |
| 3. | Газ белән тәэмин итүнең планлаштырылган күләмен кулланучының хәбәр итүе |
| 4. | Газ белән тәэмин итү шартнамәсе төзү |
| 5. | Яңа объектлар кертелгәндә, газ кулланучы объектларны чыгарганда, газны исәпләү узелын алыштырганда яки өстәгәндә, газ куллану җайланмасын алыштырганда газ белән тәэмин итү күләмнәре үзгәрсә, гамәлдәге газ белән тәэмин итү шартнамәсенә үзгәрешләр кертү |
| 6. | Газ белән тәэмин итү шартнамәсен яңа милекчегә рәсмиләштерү |
| 7. | Газ белән тәэмин итү шартнамәсен өзү |
| 8. | Бирелгән-алынган газ актларын һәм товар йөкнамәләрен рәсмиләштерү |
| «Водоканал» Казан шәһәре муниципаль унитар предприятиесе» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү өлешендә) | |
| 1. | Үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин итү һәм/яки су бүлү системасына тоташтыруга шартнамә төзү һәм техник шартларны алу |
| «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте» (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү өлешендә) | |
| 1. | «Сетевая компания» ААҖ электр челтәрләренә энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыру |
| 2. | Электр энергиясе һәм куәт тапшыру хезмәтләре |
| 3. | Электр энергиясен исәпләүне оештыру хезмәтләре күрсәтү |
| 4. | Технологик тоташтыру турында документларны тергезү һәм яңадан рәсмиләштерү |
| 5. | Аларны технологик тоташтыру вакытлыча энергия белән тәэмин итү схемасы буенча гамәлгә ашырылган энергия кабул итү җайланмаларыннан тыш, челтәр оешмасы файдасына максималь куәтне киметү күләмен яңадан бүлгән вакытта гариза бирүченең максималь куәте күләмен киметү |
| 6. | Электр энергиясен исәпләү приборлары күрсәткечләрен алу |
| 7. | Кулланучылар мөрәҗәгатьләрен кабул итү һәм теркәү |

| | |
|---|---|
| 8. | Электр белән тәэмин итү мәсьәләләре буенча консультация |
| «Татэнерго» акционерлык җәмгыяте (түбәндәге хезмәтләрне күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү өлешендә) | |
| 1. | Юридик һәм физик затлар өчен җылылык белән тәэмин итү шартнамәләре төзү тәртибе турында мәгълүмат бирү |
| Күпфункцияле үзәкләр яки алар җәлеп иткән чит оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган өстәмә (иярчен) хезмәтләр | |
| 1. | «Идентификация һәм аутентификация бердәм системасы» Федераль дәүләт мәгълүмат системасында гражданнарны теркәү |
| 2. | Криптографик мәгълүмат саклау чарасы белән җиһазландырылган цифрлы тахограф өчен йөртүче картасын әзерләүгә гаризалар кабул итү |
| 3. | Гражданнарга дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына кергән Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләре бирүгә гаризалар кабул итү». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\417.docx